| | |
|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 2 апрель г.Казань № 251

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2019 ел, 23 сентябрь, 870 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2019 ел, 23 сентябрь, 870 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 2 ноябрь, 1003 нче, 2019 ел, 28 декабрь, 1230 нчы, 2019 ел, 30 декабрь, 1249 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган 2020 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт эшләренә норматив чыгымнарда:

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2.4. | "Юл хәрәкәте иминлеге" дәүләт бюджет учреждениесе | юл эшчәнлеген тормышка ашырганда гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча чаралар үткәрү | 750 395 500,0 |
| | | гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чараларын үлчәү | 215 937 000,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрне инновацион, эшкуарлык, ирекле эшчәнлеккә җәлеп итүгә, шулай ук яшьләрнең гражданлык активлыгын үстерүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән чараларны оештыру | 30 409 600,0 |
| | | транспорт чараларын күчерүне һәм саклауны оештыру, шулай ук махсуслаштырылган стоянкаларны эксплуатацияләү (махсуслаштырылган стоянкаларны булдыру, төзекләндерү, карап тоту һәм эксплуатацияләү) | 2 022 287,03 |
| | | транспорт чараларын күчерүне һәм саклауны оештыру, шулай ук махсуслаштырылган стоянкаларны эксплуатацияләү (тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган стоянкага күчерү) | 52 016 387,68 |
| | | транспорт чараларын күчерүне һәм саклауны оештыру, шулай ук тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган стоянкаларда эксплуатацияләү (саклау һәм исәпкә алу) | 1 261 325,29»; |

8.1 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Комплекс-52» дәүләт бюджет учреждениесе»;

12.24 пунктның 4 графасында «455 600,0» саннарын "1 825 600,0" саннарына алмаштырырга;

12.25 пунктның 4 графасында «1 122 700,0» саннарын "2 195 700,0" саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән карар белән расланган 2020 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарда һәм аларның күләмнәрендә:

1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.2 пункт өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «1.2. | "Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр | дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең | 120,09 | 5 000 000,0 | берәмлек»; |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | күпфункцияле үзәкләрендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру | | | |

2 бүлек үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин